Футбол мундиалие кунаклары һәм жанатарлары Рузаевка тегv фабрикасында тегелгән киемнәрен киеп йорерләр.

Бу производствода хезмәткәрләрнен кvбесе - хатын-кыз. Тегv эшендә бvген, машиналар тосле унган куллары белән, тегvче ханымнар киемнен я бер, я икенче детален тоташтырып бара; һәрберсе vз операциясен житез һәм тогәл башкара. Берботен итеп жыйгач, жайлы һәм матур, бvгенге кон таләп иткән киемнәр барлыкка килә. Үзенен фабрикасы турында директоры Н.И. Кураева болай ди: «Без ачылганда барлыгы биредә кырык ике кеше хезмәт итә иде, ә бvген – сигезән бер кеше. Россия Федерациясе оборона Министерствосы заказын – хәрбиләргә футболкалар тектек. Бvген футбол буенча Ботендонья Чемпионатына заказны тегәбез. Мундиалий символикасы белән футболка, шорты һәм чалбар, майка, поло, свитшотлар (кvлмәк-свитер, толстовка кебегрәк) остендә эшлибез. Куелган максатларны коллектив унышлы башкара, чонки биредә хезмәт итvче кызларыбыз югары класслы тегvчеләр. Үткән ел заказлары буенча бер генә дә канәгатьсезлек белдерvче булмады».

Чынлап та, цехта эш кайнап тора һәм тегv машиналары тавышы туктаусыз гожли. Башлары машинага таба оелгән рузаевка хатыннары Ботендонья Чемпионатына киемнәр тегәләр. Кvз алдында европа стандарлары буенча тегелгән кием оемнәре vсеп тора. Алар барысы да мастерларча тегелгән.

Цех житәкчесе Т.В.Адмакина vзенен хезмәткәрләре турында зур ихтирам белән: «...кызларыбыз теләсә кайсы машина артында сыйфатлы эшли. Тегvче эше авыр: агым тосле әйберләр тегелә, тегvчедән зур игътибар һәм тvземлелек сорала. Хезмәткәрләребез барысы vз урынында лаеклы утыра, коллективта бер-берсен алыштырып эшләvнен уникаль кvренеше хужа. Бvген без европа стандартлары һәм таләпләре буенча катлаулы киемнәр тегәбез.

Һәрбер тегvчебез мактауга лаек. Эшләренә зур жавап белән якын килеп эшлиләр, безнен булган сорауларыбызны vтиләр. Мәсәлән, Надежда Росланова тегvче булып унике ел эшли инде.Ул бездә булган һәрбер машинада тегә белә. Профессиональ нечкәлекләрне бик тиз ота, яна модельләрне эшкәртv процессында катнаша, беренче vрнәк вариантын да ул тегә. Эшендә профессионал, яшь тегvчеләр белән тәжрибәсен уртаклаша. Кыскасы, һәр-бер эшкә жаваплы якын килә, ачык кvнелле, ярдәмчел».

Светлана Дубованы тегv-трикотаж фабрикасына утыз оч ел тукыманы кисv цехында хезмәт иткән әнисе Любовь Ивановна Улитина алып килгән.

«Профессиям мина бик ошый. Тырышып эшләсән, тvләv дә яхшы.

Торле милләт хатын-кызы эшли биредә: мордвалар, руслар, татарлар һәм башкалар. Коллективыбыз тату, бер-беребезгә ярдәмгә һәрвакыт әзерләр. Кирәк чакта, теләсә кайсы машина артында, бер-беребезне алмаштырып, эшли алабыз.
Безнен продукциягә, бар доньяга билгеле булган футбол мундиале символын, куелган параметрлар буенча, мультипл печать станогы белән тошереп барыла. Әзер заказны Мәскәvгә озатырлар һәм башкала кибетләрендә сатылыр. Ботендонья Чемпионаты кунаклары һәм жанатарлары без теккән поло, шортлар, чалбарлар, свитшот һәм футболкаларыбыздан йорерләр», - ди Светлана ханым.

Н.Хәлил